ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 13.07.2020

КАРАР
№ ПР-141

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының ашлык җыю сезонына авыл хуҗалыгы предприятиеләре ашлык җыю комбайннарының әзерлеге турында нигезләмәне раслау хакында**

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруда кызыксындыруны стимуллаштыру, үсемлекчелек тармагын үстерү максатларында Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ашлык җыю комбайннарының урып-җыюга әзерлеге турында Нигезләмәне 1-нче кушымта нигезендә расларга
2. Комиссия составын 2-нче кушымта нигезендә расларга
3. Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының «ТР Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең көзге урып-җыю сезонына әзерлек турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июлендәге № ПР-153 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына 1 нче
кушымта
13.07.2020 №ПР-141

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ашлык җыю комбайннарының урып-җыю сезонына әзерлеге турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ашлык җыю комбайннарының урып-җыюга әзерлеге турында нигезләмә урып-җыю кампаниясендә катнашкан хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын, хезмәт нәтиҗәлелеген арттыру, һөнәри эшчәнлекләрен кызыксындыру максатларында эшләнде.

Комбайнчыларны бүләкләү Актаныш муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

## 2. Комбайннарны контроль суктыру һәм комбайннар экипажларын бүләкләү тәртибе.

Карау ел саен район зоналары буенча уздырыла:

1. Беренче зона - Әтәс авылының басуында (МТП) Әнәк агрофирмасы ҖЧҖ, Шайчурино ЯАҖ комбайннары катнаша.
2. Икенче зона – Чалманарат авылы басуы (МТП каршысы) Наратлы, Тан, Нур, Чиялек ҖЧҖ, Агидель СПСК комбайннары катнаша .
3. Өченче зона – Аэропорт басуы Актаныш агрофирмасы, Башак, Нигез ҖЧҖ комбайннары катнаша.
4. Дүртенче зона - Богады Сәфәр-Чишмә юлы чаты Тамыр, Чишма ҖЧҖ, Чишма агрофирмалары катнаша.
5. Бишенче зона - Сәфәр-Яхшый юлы чатындагы басуда.
7. Җиденче зона-Пучы авылы басуы (МТПның арткы мәйданчыгында) Н.Баян ис.ҖЧҖ катнаша.

Ашлык җыю комбайннарының урып-җыю сезонына әзерлеген карау түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:
- комбайнны 2020 елгы уңышны җыю сезонына әзерләү;
- теоретик белемнәр (тестлаштыру);
- комбайнны эшкә әзерләү һәм эш процессы;
- эш барышында техника иминлеген белү;
- һөнәри сыйфатлар.

## 3. Бүләкләү тәртибе.

Җиңүчеләрне бүләкләү Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты раслаган комиссия карары нигезендә башкарыла, комиссия составына: Башкарма комитет җитәкчесе - Габделхаев И.И., авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең вакытлыча җитәкче вазыйфасын башкаручы - Салимгараев Н.А., авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге җитәкчесе - Мухаметдинов Д.З., Россельхозцентр ФГУ Актаныш филиалы башлыгы - Сарваров Ә.Ә. Дәүләт техник күзәтчелегенең Актаныш филиалы башлыгы - Хакимов И.М., муниципаль берәмлекнең баш бухгалтеры - Галимарданова А.А. керә.

3.1 Җиңүчеләрне бүләкләү 2 этапта башкарыла:
- кабул итүне искәрмәләрсез үткән бер комбайнга 1000 сум күләмендә,.
- теоретик белемнәрне тикшерү нәтиҗәләре буенча бер комбайнчыга 5000 сум күләмендә (Нигезләмәгә 1 нче кушымта).

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына 2 нче
кушымта
13.07.2020 №ПР-141

Комиссия рәисе:
Башкарма комитет җитәкчесе - Габдулхаев И.И.

Комиссия әгъзалары:
И.о.начальника УСХиП - Салимгараев Н.А.,
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең вакытлыча җитәкче вазыйфасын башкаручы - Мухаметдинов Д.З.,
Россельхозцентр ФГУ Актаныш филиалы башлыгы - Сарваров Ә.Ә.
Дәүләт техник күзәтчелегенең Актаныш филиалы башлыгы -Хакимов И.М.,
муниципаль берәмлекнең баш бухгалтеры - Галимарданова А.А..

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына 3 нче
кушымта
13.07.2020 № ПР-141

Теоретик һәм практик белемнәрне тикшерү нәтиҗәләре буенча иң яхшы комбайнчылар исемлеге

1.Мирзамахмутов Идьгар Тимергалиевич - Нигез ҖЧЖ

2.Ахатов Фарис Фарсиевич - Ташкын Нигез ҖЧЖ

3.Хайдаров Данил Фаритович - Башак Нигез ҖЧЖ

4.Шайдуллин Илнур Шаукатович - Чишма Нигез ҖЧЖ

5.Нуртдинов Назим Фаритович - Наратлы Нигез ҖЧЖ

6.Галлямов Алмаз Ахнафович - Өнәк агрофирмасы

7.Шангараев Альберт Миннегалиевич - Актаныш агрофирмасы

8.Аглиев Альберт Илдарович – Алга Нигез ҖЧЖ

9.Муратов Илдус Ильясович - Чәчер ЯАҖ

10.Ханнанов Ильшат Мирхатович - Нур Баян ис.ҖЧЖ